МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

05.10.2018 Казан ш. № 562-осн

2018 елның 15 маендагы 262-осн номерлы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яки урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе турында нигезләмәнең үзгәрешләр кертү турында

Федераль законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. 2018 елның 15 маендагы 262-осн номерлы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Дәүләт мөлкәтендә торучы урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү хокукына яки урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына сатулар уздыру буенча комиссиясе турында нигезләмәнең 3.2.1 пунктына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.2.1. аукцион уздыру турында карар кабул ителгән көннән башлап утыз көн узганчы һәм аукцион уздыру көненә кадәр кимендә утыз биш көн алдан; урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе төзү хокукына аукцион уздыру турында карар кабул итү көненнән соң унбиш көн узганчы һәм аукцион уздыру көненә кадәр кимендә егерме биш көн алдан;».

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми сайтында рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен контрольдә тотуны урман хуҗалыгы министрының беренче урынбасары Ә.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Министр Р.Ә.Кузюров